Казан федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе

Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр
фәнни белем бирү үзәге

# ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕЛЕМЕН ТИКШЕРҮ ТЕСТЛАРЫ ӨЧЕН КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ЭЧТӘЛЕК ЭЛЕМЕНТЛАРЫ КОДИФИКАТОРЫ

## ТӨП ДӘРӘҖӘ

КАЗАН
2024

Татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен төп дәрәҗәгә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – тест үтү эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификатор белем эчтәлегенең һәм аңа куелган таләпләрнең системалы бирелешен хасил итә. Бәяләү материаллары биремнәре өйрәнелә торган эчтәлеккә куелган таләпләргә туры китерелеп төзелде. Кодификатор эчтәлегендә төп дәрәҗәгә туры килгән биремнәргә таләпләр чагылыш таба.

Материаллар бирелеше дүрт бүлек кысасында һәм шулар эчендә бирелгән тел, стилистика, тыңланган һәм укылган текстның эчтәлеген аңлау, телдән һәм язма сөйләм материалын үзләштерү буенча белемнәрне тикшерүне күзаллый.

Кодификаторда эчтәлеге төп тематик блоклар эчендәге киңрәк булган тармаклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификаторның әлеге позицияләренең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала. Тикшерү биреме төзеләчәк эчтәлек элементының коды икенче баганада күрсәтелә.

## 1 нче бүлек. Тикшереләчәк эчтәлек элементларының исемлеге

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| **1** | | ***Системалы курс. Фонетика. Графика. Орфография. Орфоэпия*** |
| | 1.1 | Татар алфавиты. Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес язу |
| | 1.2 | Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше. Иҗек. Татар телендә иҗек калыплары |
| | 1.3 | Сүзне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре |
| | 1.4 | Интонация |
| | 1.5 | Басым. Сүз басымы. Логик басым. Синтагма басымы |
| | 1.6 | Татар телендә сузык һәм тартык авазлар |
| | 1.7 | Сөйләм агышында аваз үзгәрешләре. Авазларның позицион үзгәрешләре. Редукция күренеше |
| | 1.8 | Авазларның комбинатор үзгәрешләре. Ассимиляция күренеше |
| | 1.9 | Сингармонизм законы. Рәт гармониясе һәм ирен гармониясе |
| | 1.10 | Орфографик принциплар. Фонетик, морфологик, тарихи-традицион, график принциплар |
| | 1.11 | Татар теленең орфоэпик нормалары. Сузыкларның һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | | тартыкларның дөрес әйтелеше |
| | 1.12 | Татар теленең специфик авазлары һәм аларның язылыш үзенчәлекләре. |
| **2** | | ***Лексика. Фразеология. Ономастика*** |
| | 2.1 | Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның төрләре |
| | 2.2 | Күчерелмә мәгънәләрнең төрләре. Метафора |
| | 2.3 | Татар теленең сүзлек составы |
| | 2.4 | Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар |
| | 2.5 | Татар теленең сүзлек составы. Татар телендә гомумтөрки сүзләр һәм алынмалар |
| | 2.6 | Кулланылыш активлыгы ягыннан телнең сүзлек составы. Искергән сүзләр. Яңа сүзләр |
| | 2.7 | Татар телендә фразеологизмнар. Фразеологизмнарның төрләре |
| | 2.8 | Ономастика турында төшенчә. Ялгызлык исемнәрнең төрләре |
| **3** | | ***Морфемика һәм сүз ясалышы*** |
| | 3.1 | Сүз тамыры һәм сүз нигезе |
| | 3.2 | Татар телендә сүз ясалыш ысуллары |
| | 3.3 | Кушымчалар һәм аларны төркемләү |
| | 3.4 | Татар телендә кушымчаларның ялгану тәртибе |
| | 3.5 | Тамырдаш сүзләр |
| | 3.6 | Парлы сүзләр |
| | 3.7 | Кушма сүзләр |
| | 3.8 | Тезмә сүзләр |
| **4** | | ***Морфология*** |
| | 4.1 | Морфологиядә сүзләрне төркемләү |
| | 4.2 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем сүз төркеме. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр |
| | 4.3 | Исем сүз төркеменең грамматик категорияләре. Тартым категориясе |
| | 4.4 | Исемнең килеш, сан белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнүе |
| | 4.5 | Исемнәрнең ясалышы |
| | 4.6 | Сыйфат сүз төркеме. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат дәрәҗәләре |
| | 4.7 | Сыйфатларның ясалышы |
| | 4.8 | Алмашлык сүз төркеме. Алмашлыкларның төркемчәләре |
| | 4.9 | Алмашлыкларның төзелеше һәм дөрес язылышы |
| | 4.10 | Сан сүз төркеме. Сан төркемчәләре |
| | 4.11 | Саннарның төзелеше һәм дөрес язылышы |

| | | |
|---|---|---|
| | 4.12 | Фигыль. Фигыль нигезе |
| | 4.13 | Фигыльнең грамматик категорияләре. Барлык-юклык, наклонение, заман категорияләре. |
| | 4.14 | Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Фигыль төркемчәләре. |
| | 4.15 | Хикәя фигыль. Хикәя фигыльнең заман формалары. Хәзерге заман. Билгеле һәм билгесез үткән заман. Билгеле һәм билгесез киләчәк заман |
| | 4.16 | Теләк фигыль |
| | 4.17 | Боерык фигыль |
| | 4.18 | Шарт фигыль |
| | 4.19 | Затланышсыз фигыль формалары. Сыйфат фигыль |
| | 4.20 | Хәл фигыль |
| | 4.21 | Исем фигыль |
| | 4.22 | Инфинитив |
| | 4.23 | Рәвеш. Рәвешләрнең төркемчәләре |
| | 4.24 | Бәйләгеч сүз төркемнәре. Теркәгеч һәм бәйлекләр |
| | 4.25 | Модаль сүз төркемнәре. Кисәкчә. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы |
| **5** | | ***Синтаксис*** |
| | 5.1 | Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше һәм аның төрләре. Сүзтезмә һәм җөмлә |
| | 5.2 | Җөмләләрне төркемләү. Гади җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре |
| | 5.3 | Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| | 5.4 | Тиңдәш кисәкләр |
| | 5.5 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре |
| | 5.6 | Кушма җөмлә. Кушма җөмләләрне төркемләү |
| | 5.7 | Тезмә кушма җөмләләр |
| | 5.8 | Иярченле кушма җөмләләр. Иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләүче чаралар |
| | 5.9 | Иярчен җөмләләрнең төзелеше ягыннан төрләре |
| | 5.10 | Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре |
| | 5.11 | Иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре |
| **6** | | ***Стилистика*** |
| | 6.1 | Стилистика турында төшенчә |
| | 6.2 | Сөйләм стильләре. Матур әдәбият стиле |
| | 6.3 | Күчерелмә мәгънәгә нигезләнгән стиль чаралар |
| | 6.4 | Чагыштырулар. Метафоралар. Эпитетлар. Гиперболалар. |
| | 6.5 | Стилистик фигурлар һәм аларның төрләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 6.6 | Кабатлаулар |
| | 6.7 | Инверсия күренеше |
| **7** | | ***Сөйләм үстерү*** |
| | 7.1 | Телдән һәм язма сөйләм |
| | 7.2 | Сүз һәм җөмлә |
| | 7.3 | Текст. Текст белән эш |
| | 7.4 | Сүзләрдә авазларның ярашуы |
| | 7.5 | Татар теленең орфоэпик нормалары |
| | 7.6 | Татар сөйләм этикеты |
| | 7.7 | Диалогик һәм монологик сөйләм |
| | 7.8 | Чит сөйләм һәм аның төрләре |

## 2 нче бүлек. Тикшерелә торган төп дәрәҗәгә куелган таләпләр исемлеге

Таләпләр, системалы-эшчәнлекле юнәлешкә нигезләнеп: *1) тыңлап аңлый, укый һәм яза һәм сөйли алу; 2) гамәли күнекмәләргә ия булу, 3) белү/аңлау* бүлекләренә куела.

**Тыңлап аңлый, укый һәм яза алу** бүлегендә сөйләм эшчәнлегенең әлеге төрләре буенча тест үтүчеләрнең әзерлеге, шулай ук этномәдәни компетенциясе дә тикшерелә.

**Гамәли күнекмәләргә ия булу** бүлегендә татар теле орфоэпиясе, орфографиясе, грамматикасы һәм лексикасын үзләштерүгә, гамәли куллана алуга караган таләпләр куела.

**Белү/аңлау бүлегендә** лексик-грамматик материалны һәм этномәдәни мәгълүматны тел материалы буларак үзләштерүгә куелган таләпләр күрсәтелә.

| Таләп коды | Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге |
|---|---|
| 1 | Авазларны таный һәм аера белү |
| 2 | Татар телендәге специфик авазларны, аларны белдергән хәрефләрне дөрес әйтә һәм яза белү |
| 3 | Сүзләргә кушымчалар ялгану тәртибен белү һәм кушымчалар ялгану үзенчәлекләрен аңлау |
| 4 | Сүзләрне иҗекләргә дөрес бүлә белү |
| 5 | Сүз басымы, логик басым һәм синтагма басымын, интонацияне тоеп, дөрес куллана белү |
| 6 | Телнең лексик байлыгын тоемлау һәм белү |
| 7 | Сөйләм агышында аваз үзгәрешләре кагыйдәрен аңлау |
| 8 | Орфографик принципларны, орфографик нормаларга нигезләнеп, сүзләрнең дөрес язылыш кагыйдәләрен белү |
| 9 | Телнең сүз ясалыш үзенчәлекләрен белү |

| | |
|---|---|
| 10 | Сүзләрне иҗекләргә бүлеп, үзлегеңнән һәм кычкырып дөрес, сәнгатьле, йөгерек укый белү |
| 11 | Татар теленең орфоэпик нормаларын белү. Орфоэпик нормаларга нигезләнеп, җөмләләрне дөрес укый һәм сөйли белү |
| 12 | Грамматик билгеләренә бәйле сүзләрне аера белү |
| 13 | Сүз төркемнәренә хас грамматик категорияләрне, аларның парадигматик һәм синтагматик мәгънә төсмерләрен аера белү |
| 14 | Сүз төркемнәренең төзелеше, ясалышын һәм дөрес язылышын белү |
| 15 | Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше һәм аның төрләрен белү |
| 16 | Татар телендәге сүз тәртибен аңлап, сүзтезмә һәм җөмләләр төзи белү |
| 17 | Җөмлә кисәкләрен, җөмлә төрләрен аера белү |
| 18 | Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен дөрес куя белү |
| 19 | Кушма җөмлә төрләрен аера белү һәм иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләрен дөрес куя белү |
| 20 | Сөйләмнең стильләргә бүленешен аңлау, матур әдәбият стиленә хас стиль чараларын аера белү |
| 21 | Күчерелмә мәгънәгә нигезләнгән стиль чаралар аера белү |
| 22 | Стилистик фигурлар һәм аларның төрләре дөрес белгели белү |
| 23 | Җөмлә, текст буенча сорауларга дөрес һәм тулы җавап бирә алу |
| 24 | Уртача күләмле текстларны ишетеп, кирәкле мәгълүматны аңлый алу |
| 25 | Өйрәнгән орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләрне дөрес кулланып, язмача һәм телдән кечкенә текст төзи белү |
| 26 | Тыңланган аудиотекстның эчтәлеген аңлый һәм кирәкле мәгълүматны җиткерә алу |
| 27 | Укылган тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү |
| 28 | Төрле аралашу ситуацияләренә бәйле текстларны аңлый алу |
| 29 | Төрле аралашу ситуацияләрендә татар сөйләм этикетын дөрес куллана алу |
| 30 | Җөмлә һәм текстны йөгерек итеп, дөрес интонация белән укый белү |
| 31 | Уртача күләмле тексттагы җөмләләр арасындагы логик эзлеклелекне тоя һәм дөрес куллана белү |
| 32 | Сорау, хикәя, тойгылы җөмләләрнең интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләрен аера белү |
| 33 | Диалогик һәм монологик сөйләм үзенчәлек белү |
| 34 | Чит сөйләм һәм аның төрләре аера һәм сөйләмдә дөрес куллана белү |
| 35 | Көнкүреш темаларга караган актив лексиканы, гади сөйләмдә еш кулланыла торган грамматик чараларны белү һәм сөйләмдә дөрес куллана алу |